**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район
с.Березка, ул.Новостройка, д.15А

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Каенлык авылы, Новостройка ур., 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**26 октябрь 2020 г.** **№ 8**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль район Каенлык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 мартындагы 13 нче номерлы «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау турында» карары;

Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 мартындагы 18 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына тапшыру турында» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин